| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 12 № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 03 октябрендәге 4 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 3 октябрендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 статьяда

а) 7.1 өлешнең 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү;:

а) Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына йә татарстан Республикасы Дәүләт вазыйфасына сайлану яисә билгеләү, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куелганда;

б) муниципаль вазыйфага сайлану яисә билгеләп кую;

в) һөнәри берлек органында түләүле сайланулы вазыйфага сайлану, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында;

3) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш: а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында,

муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру; г) идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;;

б) түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә:

«3.1) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

19 статьяда:

19.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында Федераль законда һәм әлеге Нигезләмәдә каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.».

19.4.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.4.9. Әлеге Нигезләмәнең 19.1 статьясында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрләргә коррупциячел хокук бозуның башкарылуы турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек чорларын, аның отпускта булуын исәпкә алмаганда һәм коррупциячел хокук бозу башкарылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес: Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 йорт, Ялтау ав., Тынычлык урамы, 27 йорт, Бәкер ав., Нагорная урамы, 38 нче йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
"Иске Иштирәк авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Н.А. Мәҗитов